**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Коморгузинского сельского поселения Атнинского муниципального района**
422758, с.Коморгузя, ул. Татарстана, зд.40Б
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советы**
422758, Комыргужа авылы, Татарстан урамы., 40Б нчы йорт
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» октябрь 2025 ел. № 5

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2025 елның 08 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 08 ноябрь 2025 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны — Комыргуҗа авылы, Пионер урамы, 22 йорт, Комыргуҗа мәдәният йорты залы;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 04 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Ябынчы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Ябынчы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

1.3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2.“Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Ремонт, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны төзекләндерү (Ябынчы авылындагы зират территориясен чистарту (үлән чабу)).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40 йорт, Комыргуҗа авылы, Пионер урамы, 22 йортлардагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ш.М.Шарипов